Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам нуры

№ 14 (642) 21 июль, 2017 ел (1438, Шәүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Тарихыбызны барлауда аның өлеше зур

*Газетабызның актив хәбәрчесе, Башкортостанның Балтач районы имам-мөхтәсибе Рафис хәзрәт Шәйхәйдаровка “Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелде. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кул куйган указда болай диелә: “Мәдәниятне һәм рухи-әхлакый традицияләрне үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Башкортостан Республикасы Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе, Балтач муниципаль районы “Район Мәдәният” сарае” муниципаль автоном учреждениесенең XVIII гасыр мәгърифәтчесе Габдулла Галиев (Батырша) музее мөдире Шәйхәйдаров Рафис Муллаатдар улына Татарстан Республикасының “Атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исемне бирергә.”*

*Рафис хәзрәткә истәлекле билгене Татарстан Президенты татар имамнарының быел узган чираттагы җыенында тапшырды.*

*Рафис хәзрәт чыннан да Батырша хәзрәтләренең тормыш юлын өйрәнү, аның исемен мәңгеләштерү, туган як тарихын язып калдыру буенча зур эш башкара. Аның күп вакыты Уфа, Оренбург, Санкт-Петербург һ.б. архивларда эшләп уза. Рафис хәзрәтнең район, район мәчетләре, туган авылы Чуртанлыкүл авылы тарихына, якташ сугыш ветераннарына багышланган күп хезмәтләре китап булып басылып чыкты һәм меңнәрчә тиражлар белән таратылды. Шулар арасында көчләп чукындыруга каршы төшкән, бу уңайдан патшага гарызнамә язган, мөселманнарны каршылык акцияләренә күтәргән Батырша хәзрәтләренә багышланганнары тарихыбызны белү, дөрес аңлау өчен аеруча әһәмиятле. Шуңа күрә без Рафис хәзрәттән бүгенге көндә Батырша хәзрәтләренең исемен мәңгеләштерү буенча нәрсәләр эшләнүе белән кызыксындык. Ул моңа җавап итеп менә нәрсәләр әйтте:*

— Соңгы елларда Батырша хәзрәтләренең исемен мәңгеләштерү буенча күп кенә эшләр эшләнде. Иң башта басылып чыккан китапларны әйтергә кирәк. Аларның иң беренчесе Җәмит Рәхимовның “Батырша” романы булды. Аннары инде Мәсгуд абый Гайнетдиновның “Гарызнамә” хезмәте (“Иман” нәшрияты чыгарды), Фәүзия Бәйрәмованың “Баһадиршах” китабы. Фәүзия Бәйрәмованың китабы бигрәк тә фәһемле һәм чынбарлыкка туры килә торган. Искитәрлек дәрәҗәдә язылган, бөтен халык елап укырлык. Шулай ук үземнең дә “Батырша эзләреннән” хезмәтем басылып чыкты. Без аны Балтач районы хакимияте ярдәме белән мең данәдә чыгара алган идек. Казаннар аны тагын ике мең данә бастылар. Бу инде безнең өчен зур шатлык булды. Бүгенге көндә Казан мәчетләрендәге сату нокталарында минем китапны алырга була. Шулай ук үткән ел Карыш Баш — Югары Карыш авылы тарихына буенча китап чыгардык. Аның күп өлеше Батырша хәзрәткә багышланган. Анда беренче мәртәбә Батырша хәзрәтләренең нәсел шәҗәрәсе дә бирелде һәм аңа Башкортостан Фәннәр Академиясе белән килешенеп Башкортостан Фәннәр Академиясе академигы Әлфис Гаязов тарафыннан кереш сүз язылды. Һәм инде ул халык ягыннан да, галимнәр тарафыннан да бик җылы каршы алынды. Күптән түгел Караидел районы үзәгендә узган шәҗәрәләр бәйрәмендә шушы нәсел шәҗәрәсен төзүче шәхес аерым бүләккә лаек дип табылды. Шулай ук инде берничә ел элек Батырша хәзрәт туып-үскән Югары Карыш — Карыш Баш авылы мәктәбенә Батырша хәзрәтләре исеме бирелгән иде. Бүгенге көндә Иске Балтач авылының бик матур бер урамы Батырша хәзрәт исемен йөртә. Иске Балтач авылында Батырша хәзрәтнең музее дистә елдан артык эшләп килә. Һәм инде аның янәшәсендә генә Батырша хәзрәтләренең исемен йөрткән Җәмигъ мәчете. Үткән ел шатлыклы вакыйга булды — Уфа шәһәренең бик матур яңа бер урамына Батырша хәзрәтнең исеме бирелде. Шулай ук Рәсәй буенча үткәрелүче Фәезханов укулары быел Батырша хәзрәтнең тормыш юлына багышланды. Укулар 10-12 апрельдә Санкт-Петербург шәһәрендә Равил хәзрәт Гайнетдин җитәкләгән Диния нәзарәте тарафыннан оештырылды. Һәм дә инде шушында чыгыш ясаучылар тарафыннан фәнни-гамәли конференция резолюциясенә Батырша хәзрәтнең исемен мәңгеләштерү буенча пунктлар кертелде. Бу пунктларның берсе Батырша хәзрәтләренең Шлиссельбург крепостендә тоткынлыкта булганы һәм шунда шәһит китүе турында истәлек тактасы кую турында иде.

Музеебыз һәр көнне эшли. Алдан заявкалар белән дә кабул итәбез. Ерактан килгән төркемнәр булганда эш сәгате белән генә чикләнмибез. Үтеп китүчеләр, шалтыратучылар булганда кичке 8дә, 9да, хәтта 10да да экскурсияләр үткәргәнебез бар. Белешмә өчен тел. 8(34733) 2-07-73



**Рәсемдә:** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Рафис хәзрәткә “Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре” билгесен тапшыра.

## Беренче лагерьлар үз эшчәнлекләрен тәгәлләде

Чаллы мәчетләре каршында балаларның беренче көндезге лагерьлары үз эшчәнлекләрен тәгәлләде. Ял сезонын 1 июльдә “Әбүзәр” мәчете ачкан иде. Бирелдәге атналык лагерьда 7 яшьтән 14 яшькә кадәрге 40 кыз бала ял итте. Лагерь программасы шактый кызыклы булды. Кызлар ризык пешерү, кул эшләре буенча күнекмәләр алдылар, басейнда йөзделәр, атта йөрделәр, бау шәһәрчегенә барып бауларда ярыштылар. Шулай ук алар өчен дин-әхлак дәресләре дә уздырылды. Ә лагерьнең соңгы көнендә ата-аналар катнашында бәйрәм үткәрелде, анда бирелдә ял иткән һәр балага истәлекле бүләкләр бирелде.

3-9 июльдә “Ихлас” мәчетендә малайлар өчен атналык көндезге лагерь үткәрелде. Бирелдә 20 бала дин дәресләре алдылар, спорт уеннарында көч сынаштылар, паркта аттракционнарда күңел ачтылар.

“Рамазан” мәчетендә малайларның ике атналык ялы 15 июльдә тәгәлләнде. Бирелдә кечкенәләр төркемендә ял итүчеләр гарәп алфавитын өйрәнделәр, ә өлкәнрәкләр Коръән уку серләренә төшенде. Балалар футбол уйнадылар, планетарийга бардылар, электр-шоуда катнаштылар. Җәмгысе бирелдә 38 бала ял итте.

“Тәүбә” мәчетендә балаларның көндезге лагере үз эшен 10 июльдә башлады. Аңа 50 кыз һәм малай җәлеп ителде. Алар арасында күрше-тирә авыллардан да килүчеләр бар иде. Лагерь иртәнге 8 дән 15 сәгатькә кадәр эшләде. Бирелдә тәрбияләнүчеләр өчен иртәнге аш, аннары җиләк-җимеш ашы, көндезге аш оештырылды. Программада интеллектуаль уеннар, төрле эшләнмәләр ясау, әхлак дәресләре, кызыклы экскурсияләр булды. “Тәүбә” мәчетендәге лагерь 19 июльгә кадәр эшләде.

Мөхтәсибәт каршындагы “Хәзинә” клубы лагерында 32 кыз бала ял итте. Алар бирелдә ике атна дәвамында дин-тәрбия дәресләре алдылар, тәмле ашлар белән сыйландылар, күңелле уеннарда катнаштылар.

“Туфан” мәчетендә 8 кыз ял итте.

Хәзер шәһәрнең тагын берничә мәчетендә балаларның көндезге лагерен оештыру буенча әзерлек эшләре бара.



**Рәсемдә:** “Тәүбә” мәчетендә ял итүче балалар дәрестә.

# Яхшылык кына кылу

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Һәр мөселман садака бирергә тиеш». Кешеләр сорадылар: «Я, расүлуллаһ, әгәр дә аңарда бернәрсә дә табылмаса?». Ул әйтте: «Ул үзенең куллары белән хезмәт итсен, үзенә дә файда китерер, садака да бирер». Кешеләр: «Әгәр дә ул алай эшли алмаса?"- дип сорадылар. Ул әйтте: «Бәлагә юлыккан кешегә ярдәм итсен.". Кешеләр әйттеләр : «Әгәр дә ул аны да эшли алмаса?"- дип. Ул әйтте: «Ул вакытта ул кеше яхшылыкка яисә шәригатьтә яхшы күрсәтелгән нәрсәләргә өндәсен». Кешеләр аннан: «Әгәр дә ул аны да эшли алмаса?» дип сорадылар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Ул вакытта инде ул начар эшләрдән саклансын, чөнки бу гамәл дә аңарга садака булып язылыр" (Мөслим, 2380).*

Аллаһы тәгалә әйтә ки (22.77.): «… Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз һәм яхшылык кына эшләгез…»

Аллаһу тәгалә безгә гыйбадәт кылу белән бергә яхшылык кына эшләргә боера. Бу боеруда адәм баласы игътибарын гыйбадәт кылуга юнәлдерсә дә, чынлыкта, яхшылык кылу авыррак. Адәм баласы исламның биш баганасын җиренә җиткереп үтәргә тырышса да яхшылык кына эшләүгә тиешле игътибар бирми, аның әһәмиятен аңламый һәм нәтиҗәдә тиешле рәвештә үтәми һәм шуның сәбәпле белеп тә, белмичә дә гөнаһка бата. Бүгенге һәрнәрсә матди байлык белән бәяләнгән чорда ул яхшылык эшләгәнче үзенә ул яхшылык ничек кайтыр, дип, эшләгән яхшылык дөрес бәяләнерме, дип уйлый. Икенче төрле әйтсәк, үзенең яхшылыгын бурычка эшли һәм үзенә дә яхшылык белән җавап кайтармасалар эшләгән яхшылыгына үкенә. Өстәвенә «аңа ярдәм итмәгез, ул рәхмәт тә әйтә белми», дип башкаларны да котыртып йөри башлый. Бәлки ярдәм ителгән кеше рәхмәт әйтә белмәсә дә ярдәмгә мохтаҗдыр.

Мөселман кеше нинди хәлдә булуга карамастан фәкать яхшылык кына эшләргә тиеш. Ул үзен, әйләнә-тирәсен, җәмгыятен фәкать яхшылыкка өндәргә бурычлы. Бүген күпләр үзләренә нинди вазыйфалар йөкләнгәнен аңламыйлар. Шушы әхлаксызлыкка баткан, пычрак җәмгыятьтә Аллаһы тәгала безне аерып алып Ислам диненә күндергән икән, димәк без шул җәмгыятьне пакьлар өчен бөтен көчебезне куярга тиешбез. Бу имамның гына эше түгел. Без дөрес аңларга тиешбез — шунсыз безнең киләчәк юк. Ә җәмгыять исә безнең һәрберебез пакь булганда гына пакь булырга мөмкин. Шуңа күрә дә Аллаһы тәгалә «яхшылык кына кылыгыз», дип безгә боера.

Өсләренә йөкләтелгән фарыз гыйбадәтләрен кылмаган, шулай да үзләрен мөселман санаган күпләр өчен Ислам дине төшенчәсе садака бирешү белән чикләнә. Алар, күбесенчә, садаканы ниндидер кыйммәткә ия булган матди әйбер итеп күз алдына китерәләр. Шуңа күрә күпләр алырга яратсалар да бирергә яратмыйлар. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «һәр мөселман садака бирергә тиеш». Кешеләр сорадылар: «Я, расүлуллаһ, әгәр дә аңарда бернәрсә дә табылмаса?». Ул әйтте: «Ул үзенең куллары белән хезмәт итсен, үзенә дә файда китерер, садака да бирер». Кешеләр: «Әгәр дә ул алай эшли алмаса?"- дип сорадылар. Ул әйтте: «Бәлагә юлыккан кешегә ярдәм итсен.". Кешеләр әйттеләр : «Әгәр дә ул аны да эшли алмаса?"- дип. Ул әйтте: «Ул вакытта ул кеше яхшылыкка яисә шәригатьтә яхшы күрсәтелгән нәрсәләргә өндәсен». Кешеләр аннан: «Әгәр дә ул аны да эшли алмаса?» дип сорадылар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Ул вакытта инде ул начар эшләрдән саклансын, чөнки бу гамәл дә аңарга садака булып язылыр" (Мөслим, 2380).

Бу хәдистән күргәнебезчә, садака дип бөтен яхшылыкка китерә торган нәрсә дә санала. Аны мәҗлесләрдә бирелә торган хәер акчасы белән генә чикләргә кирәк түгел.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Шәригатьтә яхшы саналган һәрнәрсә садака». (Мөслим, 2375)

Әбү һөрәйрадан риваять кылына торган хәдистә пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Яхшы сүз — садака». (Бохари, 34)

Безнең халыкта Коръән укып садакалар бирешеп төрле мәҗлесләр уздыру гадәте бар. Әгәр дә яхшы сүзләр сөләшеп, бер-беребезне дингә өндәп, Коръән укып уздырабыз икән, без үткәрә торган искә алу, Коръән уку мәҗлесләре үзләре үк олугъ садака булып торалар. Ә инде ул мәҗлесләрдә дөнья сүзләре сөйләнә, шәригатьтә рөхсәт ителмәгән ризыклар, гамәлләр кулланыла икән, андый мәҗлесләрдән гөнаһтан башка нәрсә ирешмидер. Хәтта ул мәҗлесләрдә Коръән укылып садакалар өләшенсә дә. Мөмкин кадәр мәҗлесләребезне дини итеп үткәрергә тырышсак иде. Җәмгыятебез динсез булса да, кеше дә иман юк дип әйтә алмыйбыз. Ул дини йолалар булса да үткәрергә тырыша, мәчеткә Коръән укучы сорап мөрәҗәгать итә. Һәм безнең вазыйфа шушы мәҗлесләрне шәригатьчә итеп уздыру. Бу мәчеттән мәҗлескә йөрүче бабайларга гына да түгел, мәчет имамнарына гына да түгел, бәлки үзен мөселман санаган һәркемгә дә кагыла. Коръән укыла торган мәҗлесләрдә сәясәт, гайбәт кебек сүзләр булырга тиеш түгел.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Сезнең яхшыларыгыз начарларыгыздан ни белән аерылуы турында хәбәр бирергәме?» алар моңа бер сүз дә әйтмәделәр. Һәм фәкать ул бу сорауны 3 тапкыр кабатлаганнан соң гына бер кеше: «Әлбәттә, я, Расүлуллаһ, яхшыларыбыз начарларыбыздан ни белән аерылуы турында хәбәр бир», диде. Шунда ул «Сезнең яхшыларыгыз шулардыр, кемнән башкалардан яхшылык кына көтәләр һәм аның явызлыгыннан алар имин булалар, ә начарларыгыз шулардыр, кемнән башкалар яхшылык көтмәсләр, һәм аның явызлыгыннан имин булмаслар», диде. (Тирмизи, 2432)

Аллаһы тәгалә безгә мөселманнарга яхшылык кына кылуны боера. Үзеңә яхшылык эшләгән кешегә яхшылык эшләп була. Бу бозык җәмгыятьтә башкаларга сиңа яхшылык эшләүчеләр генә керми, сиңа начарлык эшләүчеләр дә керә. Ә инде аларга яхшылык эшләү булдыра алмастай эштер. Сиңа яхшылык эшләүчеләр бәлки синнән явызлык көтмиләрдер, ә бит җәмгыятьтә, һәркем үз мәнфәгатен генә караганда сиңа явызлык эшләүчеләр дә аз түгелдер һәм алар синең явызлыктан үзләрен имин дип санамыйлар бит. Шулай булгач, безнең яхшыларыбыз бармак белән генә санарлыктыр. Ә бит пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

«Сезнең берегез дә үзенә теләгәнне үзенең туганына теләми торып, иман китерүчеләрдән булмас». (Бохари, 13)

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Мөселман мөселманга туган, һәм ул аны кысырыкламасын һәм ярдәменнән ташламасын. Үзенең туганының ихтыяҗларында ярдәм итүчегә Аллаһы тәгалә үзенең ихтыяҗларында ярдәм итәр, мөселманны берәр кайгыдан коткарган кешене Аллаһы тәгалә кыямәт конендә үзен дә берәр кайгыдан коткарыр. Мөселманның гаебен яшергән кешенең кыямәт көнендә Аллаһы тәгалә үзенең дә гаебен яшерер». (Мөслим, 6743)

Без мәчеткә төрле холык, төрле уй-фикерләр белән җыелабыз. Арабызда төрле милләт вәкилләре, төрле байлыкка, дәрәҗәләргә ия булулчылар бар. Әгәр без үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, без үзара туганнар. Мин-минлегебезне җиңеп, без шушы кагыйдә белән килешергә тиешбез. Безнең үзара мөнәсәбәтебез ничек булса, Аллаһы тәгаләнең дә безгә карата мөнәсәбәте шулай булачак. Барыбызны да көтә торган Кыямәт көнен онытмыйк: үзара мөнәсәбәтебезгә карап кыямәт конендә безгә дә мөнәсәбәт шулай булачак.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Әгәр берәү үзенең туганының хаҗәтләрен үтәү өчен ярдәмгә юнәлсә, бу аңа 10 ел мәчеттә булудан хәерлерәк, ә Аллаһы ризалыгына омтылып мәчеттә бер генә көн уздырган кешене дә Аллаһы тәгалә уттан 3 чокыр белән аерыр, ул чокырларның һәрберсенең киңлеге көнбатыш белән көнчыгыш арасына тиңдер». (Әл-мугҗимул-Әүсатыйл-лит-Табарани, 7537)

Бүген кайберәүләр башкаларның гыйбәдәтләрен тикшереп, башкаларны кәферлеккә чыгарып, Аллаһы тәгаләнең кайдалыгы, заты, тәкъдир кебек Исламда тыелган темаларга зур-зур бәхәсләр кубарып йөрергә яраталар, «Хәлифәт төзергә кирәк», яисә «хак Ислам урнаштырырга кирәк» дип төрле партияләр, фиркалар төзеп, башкаларны шул партияләргә, фиркаларга чакырып, бөтен гомерләрен үти алмастай хыяллар белән уздыралар, гади генә бөтен кеше дә үти алырдай гамәлләрне игътибарсыз калдыралар. Ә бит шул гамәлләр кешене җәннәтле итә. Һәм без дә шул җәннәткә омтылмыйбызмыни? Җәннәткә бит башкаларны кыерсытып, рәнҗетеп кереп булмый. Җәннәткә фәкать башкаларга яхшылык эшләп, башкаларны ихтирам итеп, тәкәбберләнмичә, түбәнчелекле булып кына ирешергә була

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Мин юлда мөселманнарга кыенлык тудырган агачны читкә алып куйган өчен җәннәттә җәннәт нигъмәтләре белән хозурланучы кешене күрдем». (Мөслим, 6837)

Аллаһы тәгалә һәммәләребезне дә фәкать бер-беребезгә яхшы нияттә, яхшы мөнәсәбәттә генә була торган, башкаларны бары яхшылыкка гына өнди торган мөселман туганнардан булуыбызны насыйп итсә иде.

**Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли,**
**Чаллының "Ак мәчет"е имам-хатыйбы, төбәк казые**

# Хәзрәтебезне зурладык



Чаллының "Туфан" мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Нуруллинга 60 яшь тулды. Шушы уңайдан без, мәхәллә кешеләре, мәчет картлары, мөгаллимәләр Равил хәзрәтне гомер бәйрәме белән тәбрик итеп мәҗлес үткәрдек. Аңа үзебезнең рәхмәтләребезне белдереп бүләкләр бирдек, рәхмәт йөзеннән күп матур сүзләр әйтелде.

Равил хәзрәт "Туфан" мәчетен төзүдә күп көчен куеп Аллаһының рәхмәтен өмет итеп хәзерге көндә дә үзенең фидакарь хезмәтен куя. Үзе генә түгел, хәзер инде гаилә әгъзалары да шушы мәчет тормышына үзләренең хезмәтләрен кертәләр. Мәчеттә ир-атлар һәм кыз-хатыннар өчен уку-укыту эшләре дә киң рәвештә куелган. Һәр җәйдә мөселман балалары өчен ике атналык лагерьлар оештырыла. Аллаһы Тәгалә аңа киләчәктә дә шулай уңышлы итеп эшләргә ярдәм бирсен. Тагын да озак еллар безнең имам булып калуын Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз.

**Мәхәллә кешеләре**

**Рәсемдә:** Равил хәзрәт дүрт яшьлек оныгы Кәрим (быел Коръән уку бәйгесендә иң яшь катнашучы булды) белән.

## Татар улы татармын! Ислам динен тотармын!

Азан. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләнең йортына килеп намаз укырга чакыра. Кемдер мәчеткә ашыга. Кемдер садака салып китә. Кемдер имамның намаз укып бетергәнен көтеп утыра.

Күпме кеше бер нәрсәгә игътибар итмичә үтеп китә.

Ни хәл соң бу? Ник татар халкы мәчеткә йөрүне кирәк санамый?

Без бөек халык булырга омтылабыз. Тарихны, 15-16 гасырларны искә төшереп, без шундый булган, безне яулап алып кына харап иткәннәр дип. Ә кем гаепле? Сәбәбе? Аллаһы Тәгаләдән ерагайгач Ул үзенең ярдәменнән ташлаган безне.

## Хәзер кем комачаулый бөек булырга?

Йөрик мәчеткә. Коръән укырга өйрәник. Тотыйк ураза. Түлик зәкәт. Барыйк хаҗга. Дингә каршы килми торган йолаларны саклыйк. Тырышып эшлик. Кем комачаулый безгә? Хәзерге көндә дә данлыйк татар халкын. Белемле, итагатьле, тәртипле, тырыш, чиста халык итеп. Шул булыр безнең бөеклек. Кирәкми безгә Кытайдан яңа елны нинди хайван елы килүенә карап нинди кием киеп каршы алырга өйрәнү. Алар кебек тырышып эшләргә өйрәник. Европадан өйрәник бер беребезгә яхшы мөнәсәбәткә. Сайлана, сайлана сыра я шәраб эчәргә түгел.

## Исламны тәнкыйтькә алу бик җиңел

Бер яктан - Исламда бөтен кеше белән булырга мөмкин халәтләр ачыктан-ачык карала, алар турында турыдан-туры языла. Яхшысы турында да, яманы турында да. Исламда кеше карала ихтыярлы дип, яхшысын да, яманын да эшләвен үзе сайлый, шуның өчен үзе җавап бирәчәк дип. Бу очракларда нәрсә эшләргә кирәге турында анлатыла.

Икенче яктан — дөньяви җәмгыять. Монда инде кимчелекләр урап үтелә. Кешеләр гел яхшы уйда, яхшы гамәлдә дип карала. Ни өчен? Чөнки күп нәрсәгә күзне йомсаң яшәү җиңелрәк. Алдыйбыз үзебезне, бер-беребезне. Була торган хәл. Матур сөйли белергә генә кирәк.

## Татар халкы мәчеткә йөрүдәнояла

Анда кара, белемсез халык кына йөри, дип үзен бик өстен куя. Маркс теориясе буенча мәчет урынына театрга йөри. Уйлана. Дулкынлана. Караватны аркылыга йә буйга куйсан йорт бәхетле буласына ышана - феншуй була инде ансы.Тагын бик күп нәрсәгә ышана, аларны эшләргә иренми, вакыт таба. Аллаһы Тәгаләнең йортына килеп намаз укуның кирәклегенә генә ышанмый

## Мәчеткә килсә нәрсә көтә?

Мәчеткә килгән кешедә инде өмет бар. Аны өзмәскә кирәк. Бер утырып сөйләшүгә намазга бастырам мин моны, дип уйламаска. Белем алырга чакырырга. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Гыйлем өйрәтегез, җиңеләйтегез, әмма авырайтмагыз, сөендерегез, әмма нәфрәтләндермәгез", - дип әйтә. Белем алгач кеше үз юлын таба Аллаһы Тәгаләгә таба. Хәләл ризык турында. Хәләл эш турында. Ураза турында. Кайсысында да булса эшли башласын кеше.

Институтка укырга килгән кешене бер утырып сөйләшүдә дипломлы белгеч итеп кайтарып җибәрмиләр бит.

Дингә керсәң бөтен нәрсәне кире кагырга дип өндәргәме?

Ә болай да эчми йөрсә? Балаларына яхшы тәрбия, белем бирергә омтылса? Кешеләргә һәрвакыт яхшы мөнәсәбәттә булса?

Ул дингә килсен дә, бөтенесен үзгәртсен дип дәгъвәт кылыргамы?

Болай син яшәмә, һәлакәткә барасың, үзгәрт бөтенесен дипме?

Бәлки аңа икенче яктан килергә? Син бит инде болай да Исламга якын, әз генә адым ясa дип? Урта гасыр яшәү рәвешенә чакырыргамы? Яисә сәхәбәләрнең нәрсә турында сөйләшкәне, борчылганы, уйланганы турындамы?

Чүл уртасында 7-че гасырда гарәпләр калебне сафландыру сораулары белән кызыксынган, Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә белән кешенең мөнәсәбәте турында фикер йөрткәннәр... Ә хәзер? Ихлас сүрәсенең мәгънәсе турында кем уйлана? Ә ничек сарык суярга - ул турыда галимнәр күп! Эт белән булышу темасына диссертация язырга әзерләр бар!

Үз вакытында мөселманнар тирә-як халыкларга караганда нәрсә белән аерылган? Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән табыну, кешеләргә, хайваннарга яхшы мөнәсәбәт, сәүдәдә гаделлек, эшләрендә тәртип, белемле булулары, үз вакыты өчен иң алдынгы булулары белән.

Татарларның тормышын яңа дәрәҗәгә күтәрү өчен бүгенге көндә дә безгә шушы сыйфатларны үзебездә булдыру һәм үстерү өстендә эшләргә кирәк. Аллаһы Тәгалә : "Миңа таба бер адым атласагыз, Мин сезгә ун адым атлыйм. Миңа каршы атлап килсәгез, Мин сезгә каршы йөгереп киләм,"- ди (Хәдис).

**Илдар хәзрәт Зияров,**
**Чаллы "Хәләл-Үзәге".**

# Тәнзилә абыстай: "Гыйбадәтләребезне, хаҗларыбызны соңга калдырмыйк"

Аллаһ Раббыбызга хәмед-сәнәләребез, мактау догаларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебездән чыккан салават шәрифләребез ирешеп торса иде. Раббым Аллаһка мең-мең шөкер безне туры юлга бастырып Үзенә гыйбадәт кылырга насыйп иткәнгә. Шуңарга шатланып бетә алмыйбыз иптәшем белән.

Дүрт тапкыр хаҗ гамәлен үтәгәннән соң (ул вакытта — 2000 елдан бирле эштән китеп әнине карый идем), 2008 елда аяк буыннарым шешә. Намаз укыганда сәҗдәгә бару бик авыр иде. Шулай да утырып укырга тырышмадым. Бер хаҗга баргач, анда гел барасы килеп тора. Барган кешеләр ул галәмәтне беләләр инде. Бер көнне иртәнгә намаздан соң дога кылганда: "Йә, Раббым, минем чирләвем шушыдыр, инде башка хаҗга бара да алмам инде,"- дип еладым. Җәй көннәрдә иртәнге намаз 1ләрдә, 2ләрдә укыла. Аннан соң ятып йоклыйсың. Шушы көнне төш күрдем: күктә туп-тулы ай. Аның эчендә аска, хаҗ, дип язылган иде. Мин һәм минем янда иптәшем, аннан соң безнең артта ир-атлар, хатын-кызлар: "Хаҗ, хаҗ!"- дип кычкырдык. Аннан соң айның эчендә 6 саны язылган иде. Тагын берничә сан айның тышкы ягында. Мин йокыдан торгач: "Йә, Раббым, безгә 6 тапкыр барыргамы, әллә 6 нчы тапкыр барыргамы?"- дидем. Шуннан соң - әни вафат булганнан соң, аның өчен иптәшем һәм мин үземнең әнием өчен 2011 елда бардык бишенче тапкыр. Хаҗ гамәлләрен үтәп кайтканнан соң, безгә: "Нишләп сез гел Олуг хаҗга барасыз, сез бит инде үз өстегездән фарызны төшердегез, Рамазан аенда Кече хаҗ кылыгыз. Рамазан аенда Гомрә (кече хаҗ) үтәүнең пәйгамбәребез (с.г.в.) белән бергә хаҗ үтәгән савабы була",- диделәр. Без ул турыда белә идек. Әмма Олы хаҗны өстенрәк күрдек. Шулай да без тагын өч елдан — 2013 елда Гомрәгә барырга ниятләдек. Үзебез белән апаны да, бергә хаҗга барган Нургаян апаны да барырга үгетләдек. Шулай итеп без 4 кеше һәм Чаллыдан тагын без белгән берничә кеше бергә бардык. Баруларның, кайтуларның, әлхәмделиллаһ, хәзер берниндиавырлыгы да юк. Бер тәүлектә Мәккәдә буласың. Әмма ул елны без башта Мәдинә шәһәренә бардык. Мәккәгә кузгалыр көнне — 9 июльдә уразага кердек. Ихрамга кереп Мәккәгә киттек. Көннәр озын, Гомрәне үтәгәннән соң Коръән укыйсың күбесенчә. Көненә бер мәртәбә әл-Хәрәмгә барасың, анда хәленә карап ничә тапкыр тәваф үти аласың — шул кадәр үтисең. Намаз вакыты туры килсә, намаз укыйсың. Аннары кунакханәгә кайтасың. Тәвафны инде нәселдә кемнәр бар — барсы өчен дә үтәп була. Шуннан да зур әҗер-савап юк. Безгә хәтле булып киткән әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез һәм балаларыбыз, оныкларыбыз өчен үтәргә була, иренмәскә генә кирәк. Без дога кылмасак аларга кем дога кылсын. Без, әлхәмделиллаһ, ул мөмкинчелекне ычкындырырга тырышмадык.

Бер чакны Коръәнне укып чыккач пәйгамбәребезгә (с.г.в.) багышладым. Әлегә кадәр аңа багышлаганым юк иде. 2014 елны яңадан Гомрәгә киттек. "Идел-тур" аша. Аяз хәзрәт җитәкчебез иде. Бер айга дип барган идек, 40 көн булдык. Ул елны без үз туганнарыбыз белән бардык, 5 кеше. Безнең белән Арчадан күзләре күрмәүче малай да бар иде, Марат исемле. Алабугадан да безнең танышлар бар иде, алар белән дә күзләре күрмәүче бер әби барды. Күзләре күрмәсә дә гамәл кылырга атлыгып торалар, мин күрмим, дип әйтмиләр. Ә акчалары, исәнлекләре булганнар юлга чыгарга куркып торалар. Үзләре өчен нинди хәерле гамәл икәнен белсәләр, хәзерге заман җиңеллекләреннән куркып утырмаслар иде. Иптәшемнең бабасы Самигол бабай хаҗда ярты ел йөреп кайткан. Нинди авырлыклар белән барганнар, акчалары беткәннәр ялланып акча эшләгәннәр. Шулай да куркып тормаганнар, юлга чыкканнар. Самигол бабай исән-сау әйләнеп кайткач: "Улымны, Алла боерса, яшерәк чагында җибәрәм,"- дигән. Һәм улын 40 яшендә хаҗга җибәргән. Раббыбыз безгә хәзерге вакытта олуг һәм кече хаҗны үтәүне җиңеләйтте. Без шулай да дөнья мәшәкатеннән аерыла алмыйбыз. Безгә һаман җитми. Ул бер кайчан да җитмәячәк. Кешенең карынын үлгәч балчык кына тутырыр. Ә бит ахирәтне кем уйларга тиеш соң синең өчен? Үз-үзебезгә дошман булмыйк инде, җәмәгать. Ничек булса да исәнлек булганда гамәл кылырга тырышыйк. Әле ерак китәргә юк — без яшь чактагы яшәүләр белән чагыштырып карыйк бүгенге тормышны. Кечкенә генә 4 почмаклы өйдә 12шәр кеше яшәдек. Әле шунда сыерын да кертеп савалар, бозавын да кертәләр иде. Эшен дә эшләделәр, намазларын да калдырмадылар, уразаларын да тоттылар. Җәй айларында басуларда техника юк чакларында әнинең әйткәне исемдә: "Күрше апаның ашарына юк иде, какы ашап булса да уразага керә, какы белән авыз ача иде." Нинди ихласлы кешеләр булган. Ә хәзерге заманда ураза тотмас өчен үзебезгә сәбәпләр эзлибез. Нәрсә генә эшләсәк тә, кылган гамәлләребез үзебезгә, үкенергә калмасын. Аллаһ Үзенә гыйбадәт кылучыларны беркайчан да ташламый. Чын күңелдән Аңа тапшырып гамәлеңне үтәргә генә кирәк.

2014 елдагы Гомрәдә мин тагын Коръән укып пәйгамбәребезгә (с.г.в.) багышладым. Һәм шул көнне ул төшемә керде. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Ураза аенда шайтаннар богауда булырлар һәм кем мине төшендә күрсә, ул мине хак күргән булыр,"- дигән сүзе бар. Төшемдә аның белән очрашырга дип бардым. Алар сәхәбәләре белән килделәр дә, эшләрен тәмамлап китеп бардылар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) минем якка борылып та карамады. Мин инде ачырганып: "Минем бит аның белән сөйләшәсем килгән иде,"- дидем. Янымда бер кеше юк иде. Нииндидер тавыш: "Шушы вакытта шушы җиргә килергә тиешләр, шунда бар,"- диде. Мин шунда киттем һәм көтеп тордым. Чынлап та килделәр, ерактан

ук мине күреп елмаеп яныма килде. Аның матурлыгы, нурлы йөзе сөйләп бетерерлек түгел. Килүенә мине кочаклап алды һәм ике битемнән үпте. Мин: "Синең белән бергә буласым килә,"- дидем. Ярар да димәде, елмаеп карады да киттеләр. Алар киткәч әлеге тавыш миңа яңадан: "Ул бит инде карт,"- ди. Мин: "Нишләп карт булсын, әле аңа 60 кына яшь,"- дидем. Иптәшемә сөйләдем. Ул: "Мин анда юк идемме?"- диде.

Уразаларны хәзерге вакытта тоту бик җиңел. Мәккәдә дә ифтарга һәр көнне кайнар ризык китереп тордылар. Аяз хәзрәткә Аллаһның рәхмәте яусын. Без инде аның белән быел 3нче тапкыр Гомрәгә бардык — 2015 һәм 2017 нче елларда. 2015 елда да Мәккәдә Коръән укып багышлагач пәйгамбәребез (с.г.в.) яңадан төшкә керде. 2014 елда кайткач төшне танышбелешләргә сөйләгән идем. Алар: "Сорадыңмы соң, син җәннәтлеме, юкмы?"-диделәр. Мин инде: "Юк,"- дидем. Шуңа күрәме, пәйгамбәребез (с.г.в.) яңадан төшемә керде. Ике чират кешеләр. Бөтенебез дә ак киемнән. Мин пәйгамбәребезне (с.г.в.) күрдем дә: "Карагыз әле, әнә бит пәйгамбәребез анда басып тора,"-дидем. Бардым да садака бирдем. Минем арттан бөтенесе садака бирә башлады, күп-күп иттереп. Әй мин оялдым, минем биргән садакам әз булганга. Бераз бардык та, туктап ял иттек. Аннан соң яңадан кузгалдык. Күпмедер барганнан соң яңадан туктап ял итәргә утырдык. Шунда мин аның янына килдем дә: "Әй, Аллаһ Тәгаләнең илчесе,



миңа әйт әле, мин җәннәтлеме?"-дидем. "Әйе,"- диде. "Мине шатландырганың өчен Аллаһның рәхмәте яусын,"- дидем. Ул миңа: "Тик тәкәбберләнмә!"-диде. Мин инде аңа: "Юк, юк, миндә андый гадәт юк,"-дидем. Аннан соң ул ятып тора иде, өстенә тау хәтле дөге ярмасы өелде. Мин борчылып: "Әй, Раббым, сулыш ала ала микән,"- дип карап тордым.

Быел 2017 елда да Гомрәгә бардык. Быел инде 3 атнага гына, иптәшемне эштән бик җибәрәселәре килмичә генә җибәрделәр. Эш вакыты, һәрберсенең бакча —ялсыз эшлиселәре килми. Быелгы уразаны да Мәккәдә тотарга насыйп итте. Уразага Казан аэропортында ук ниятләп сәхәр ашадык. Казаннан Төркиягә очтык, аннан Җиддәгә. Ихрамга Төркиядә кердек. Мәккәгә килеп җитеп кунакханәгә урнашып беткәнче әле ифтар вакыты кермәгән иде. Безгә авыз ачарга Аяз хәзрәт кайнар ризыклар китерергә инде сөйләшкән булган. Безнең исебез китте — безгә ризыклар китереп бирделәр, Аллаһның рәхмәте яусын. Эшләрендә уңышлар насыйп итсен, исәнлек-саулык һәм гаилә бәхете, балаларының игелеген күрергә Раббым насыйп итсен үзенә. Без барыбыз да бик рәхмәтле аңа.

Икенче көнне Гомрә үттек. Мәккәгә 10нчы тапкыр килүебез булса да, Кагъбәне күргә күздән яшьләр тәгәрәп төшә. Нинди хикмәттер, аны берничек тә аңлатып булмый. Тәваф, сәгый кылганда да күздән яшьләр кипмәде.

Раббыбызга чын күңелдән рәхмәт әйтә-әйтә, бабаларыбызның нинди авырлык белән хаҗ кылуын искә



төшереп, безнең хәзерге вакытта Олуг хаҗ һәм Гомрә кылуларны нихәтле җиңеләйткәненә шөкер итеп гамәл кылдык. Мәккәдә гаетне искитәрлек бәйрәм итеп үткәрәләр. Аны гаетне шунда каршы алган кеше генә күз алдына китерә ала. Минем исем китте андагы галәмәтләрне күреп. Бездәге яңа ел бәйрәмнәре дә янында тормый. Анда чын күңелдән гаетне бәйрәм итәләр.

Быел инде Ураза гаетен үзебездә каршы алырга насыйп булды. Калган 10 көн уразаны кайткач тоттык, әлхәмдүлилләһ. Аяз хәзрәт безне аэропортта ифтар заказать итеп ашатты. 18 кеше идек. Аллаһның рәхмәте яусын! Сәхәрне самолетта ашадык. Анда Төркия компаниясе махсус тестә сәхәргә ризыклар әзерләп безгә бирделәр. Гыйбадәт кылучыларга Раббым бөтен җайларын-җиңеллекләрен тудыра. Без шунда да иренәбез, зарланабыз. Хәзерге тормышыбызны әбибабайларыбыз тормышы белән чагыштырып карыйк әле — җир белән күк арасы. Тора торган өйләребезне генә карыйк. Һәм нинди генә ризыклар ашамыйбыз, өстәлебез тулы ризык. Күп эшләребезне Раббым Аллаһ шул хәтле җиңеләйтте, аны санап та бетерә торган түгел. Бу нигъмәтләрне барсын да Раббым Аллаһ бирә, хәзерге вакытта безне барлык белән сыный. Булганына шөкер итик. Раббым Аллаһ бирмәсә беребез дә мондый нигъмәтләр эчендә яши алмыйбыз. Хәзер инде ашсуны да күбебез өйдә пешереп тормый, ялкаулыкка өйрәнеп беттек. Шушы нигъмәтләргә шөкер кирәк, җәмәгать. Тәүбә итеп, шөкер кылып яши башласак, Раббым Аллаһ нигъмәтләрегезне арттырырмын дип вәгъдә итә. Гамәл булмаса Рабыбым Аллаһның газабы каты. Хәзерге вакытта Раббымның кисәтүләре күренеп тора: яңгырлары белән сыный, чәчкәннәр дә үсми, яңгыр яуса да. Менә шунда күрәбез үзебездән бер нәрсә тормаганны, булдыра алмаганыбызны. Раббым Аллаһ бирсә була, бирмәсә юк. Алдан кечкенә бәлаләр белән сынармын, тәүбәгә килмәсәгез зурысын бирермен, ди. Шуңа күрә тәүбәгә килергә, шөкер итәргә ашыгыйк, соңга калмыйк. Бу дөнья малы безнең өчен күпме күп булган саен аның җавабы да шуның хәтле була. Мондагы мал үлгәннән соң монда кала. Ә гамәл үзебез белән бара. Кемнең теге дөньяда җәннәт әһеле буласы килсә, исәнлеге булганда, яшь чакта гамәл кылырга тырышсын иде. Иртәгә нәрсә буласын беребез дә белмибез. Соңга калуыбыз бар.

Аллаһы Раббыбызга шөкерләребезне, гыйбадәтләребезне арттырыйк. Мөмкинчелекләре булганнар кичектермичә өсләрендәге бурычларын, хаҗларын үтәсеннәр. Гомрәләргә барыйк, месккеннәрнең, мохтаҗларның хәлен белик.

**Тәнзилә абыстай Гыйрфанова**

**Чаллы шәһәре.**

**Рәсемнәрдә:** 2014 ел Рамазанында Гомрә хаҗында сәгый кылу — алгы сафта уртада Тәнзилә абыстайның тормыш иптәше Рифкать хаҗи; әл-Хәрәм мәчетендә.


## Танышырга телим

Чаллыда яшәүче 45 яшьлек ялгыз ханым (фатиры бар) ялгыз булган тәртипле татар кешесе белән гаилә корырга тели. Тел. 89274700418

* * *

Чаллыда ялгыз яшәүче 56 яшьлек ханым (торыр урыны бар) 60 яшькә кадәрге тәртипле, ялгыз татар кешесе белән никахлашырга тели. Якын-тирә авылга күчеп китәргә дә риза. Тел. 89600791008

* * *

Чаллыда ялгыз яшәүче 78 яшьлек татар карты (фатиры бар) тормыш иптәше эзли. Тел. (8552) 59-07-07



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы**
**ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7–0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**21 июль 16 сәг.**
**фактта 21июль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**